РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Уразаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района
ул. Н.Бадертдинова, д. 35,
Азнакаевский район, с.Уразаево,
423303, тел./факс (885592)43-5-55
E-mail: Uraz.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Уразай авыл җирлеге
башкарма комитеты
Н.Бадертдинов ур., 35 йорт, Азнакай
районы, Уразай авылы, 423303
тел./факс (885592)43-5-55
E-mail: Uraz.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30 гыйнвар 2026 ел** **№ 1**

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, 2026 елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 9 678 (тугыз мең алты йөз житмеш сигез) сум 63тиен күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай Башкарма комитеты 28.01.2025елгы 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: Д.И.Мутыгуллина

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына №1 нче кушымта
30. 01.2026 № 1

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының
«Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
бәясенең чик күләме

| № | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 200,00 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 2 000,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 478,63 |
| 4 | **Барлыгы** | **9 678,63** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына №2 нче кушымта
30. 01.2026 № 1

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | **Наименование услуг** | **Стоимөсть услуг, руб.** |
|---|---|---|
| 1 | Тәнне киму | 1 600,00 |
| 2 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2600,00 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 2 000,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 478,63 |
| **5** | **Барлыгы** | **9 678,63** |